ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның 3 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) егерменче абзацта «муниципаль берәмлектә» сүзләрен төшереп калдырырга, «i-муниципаль берәмлегенең» сүзләрен «i-муниципаль берәмлекләренең» сүзләренә алмаштырырга;

2) егерме икенче абзацта «муниципаль берәмлектә» сүзләрен төшереп калдырырга, «i-муниципаль берәмлегенең» сүзләрен «i-муниципаль берәмлекләренең» сүзләренә алмаштырырга;

3) егерме өченче абзацта «, i-муниципаль берәмлегенең транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтә торган t-автоматлаштырылган система операторы белешмәләре буенча, шәһәр юлларында һәм шәһәр яны юлларында даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутларында муниципаль берәмлекләрнең барлык

транспорт оешмалары тарафыннан пассажирлар йөртүләрнең (транзакцияләрнең) айлык уртача санынннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) егерме җиденче абзацта «муниципаль берәмлекләрнең барлык транспорт оешмалары тарафыннан» сүзләрен «і-муниципаль берәмлекләренең транспорт оешмалары тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 25 сентябрь
№ 55-ТРЗ